ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
28.02.2025

**К А Р А Р**
№ 258

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашырган мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2024 елның 15 октябрендәге 955 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 02 июлендәге 546 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашырган мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2024 елның 15 октябрендәге 955 номерлы карарының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашырган мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар» 5 пунктын яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Карарны интернет челтәрендә "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2025 елның
28 феврале 258че нормерлы

5. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативлары

<table>
<tr><td rowspan="3">Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының эш сәгатьләре саны</td><td colspan="4">Азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативлары, көнгә сум/тәрбияләнүче</td></tr>
<tr><td colspan="2">гомумүстерелеш төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәге)</td><td colspan="2">шифаханә төркемнәре</td></tr>
<tr><td>2 айдан 3 яшькәчә</td><td>3 яшьтән мәгариф мөнәсәбәтләре туктатылганчы</td><td>2 айдан 3 яшькәчә</td><td>3 яшьтән мәгариф мөнәсәбәтләре туктатылганчы</td></tr>
<tr><td>3-4</td><td>33,88</td><td>42,65</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>5-6</td><td>81,28</td><td>102,39</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>7-12</td><td>135,49</td><td>170,64</td><td>175,78</td><td>234,39</td></tr>
<tr><td>24</td><td>169,34</td><td>210,66</td><td>219,73</td><td>289,36</td></tr>
</table>